# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**№ 2** **21.10.2022 ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
районы Чубар-Абдул авыл җирлегенэ
керүче Чубар-Абдул авылында 2023 елда
үзара салым жыюны кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлегендә халык җыены карар бирә:

1. 2023 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Чубар-Абдул торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 350 сум күләмендә үзара салым кертү.

2. Бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү:
   - Чубар-Абдул авылында «Яңа ел», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне») бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү;
   - Чубар-Абдул авылында урамнарны яктырту өчен яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, энергияне саклый торган лампалар урнаштыру, эшләр өчен түләү;
   - Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча чаралар (янгын сүндерү җиһазлары һәм материаллары сатып алу)
   - Зират коймасы өчен материаллар алу, зират коймасы ясау һәм урнаштыру.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, кабул ителгәннән соң, 10 көннән соң, соңга калмыйча түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адрес буенча

урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга: ТР, Азнакай муниципаль районы,Чубар-Абдул авылы, Совет урамы, 85йорт.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Чубар-Абдул авыл җирлеге башлыгы: Н. Ә. Фәтхетдинов